ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5 ноябрь 2020 ел с. Ульянково № 4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Воскресенский торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Воскресенский авылы, Леваневского урамы адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Воскресенский торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын 2020 елның 26 октябрендә 11 сәгать 30 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Воскресенский авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга

http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**